МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.06.2019 г. Казань № 280

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 17 маендагы 226 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 17 маендагы 226 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 19 ноябрендәге 541 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктта алтынчы абзацтагы «2020» цифрларын «2021» цифрларына алмаштырырга;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупциячел торышка сабырсызлык формалаштыру.»;

5.12 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.».

Министр в.б. – беренче урынбасар,
Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне
үстерү департаменты директоры Р.Р.Сибгатуллин